КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 февраль г.Казань № 84

«Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын раслау турында

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, экология чылбырында иң мөһим звено буларак елгаларны саклап калу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

2. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

«Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре үзгәрү турында «Роскадастр» гавами хокук компаниясенә билгеләнгән тәртиптә белешмә кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин